МИНИСТЕРСТВО ПО ДЕЛАМ
ГРАЖДАНСКОЙ ОБОРОНЫ
И ЧРЕЗВЫЧАЙНЫМ СИТУАЦИЯМ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ГРАЖДАННАР ОБОРОНАСЫ
ЭШЛӘРЕҺӘМ ГАДӘТТӘН ТЫШ
ХӘЛЛӘР МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** г. Казань **БОЕРЫК**

06.09.2017 № 498

**Татарстан Республикасы гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгында норматив хокук актларның һәм норматив хокук акт проектларының коррупциягә каршы экспертизасы турында**

“Норматив хокук актларның һәм норматив хокук акт проектларының коррупциягә каршы экспертизасы турында” 2009 ел 17 нче июль № 172-ФЗ Федераль законына, “Норматив хокук актларның һәм норматив хокук акт проектларының коррупциягә каршы экспертизасы турында” 2010 ел 26 нчы февраль № 96 Русия Федерациясе Хөкүмәте карарына, “Аерым норматив хокук актларның һәм норматив хокук акт проектларының коррупциягә каршы экспертизасын үткәрү тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында” 2009 ел 24 нче декабрь № 883 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карарына туры китереп, б о е р а м:

1. Кушылган Татарстан Республикасы гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгында норматив хокук актларның һәм норматив хокук акт проектларының коррупциягә каршы экспертизасын үткәрү тәртибен расларга.

2. Биредәге боерыкны үтәү контролен министр урынбасары Н.В. Суржкога йөкләргә.

Министр Р.Җ. Хәбибуллин

2017 ел 6 нчы сентябрь № 498
Татарстан Республикасы
Гражданнар оборонсы эшләре һәм
гадәттән тыш хәлләр министрлыгы
боерыгы белән расланган

# ТӘРТИП
# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ГРАЖДАННАР ОБОРОНАСЫ ЭШЛӘРЕ ҺӘМ ГАДӘТТӘН ТЫШ ХӘЛЛӘР МИНИСТРЛЫГЫНДА НОРМАТИВ ХОКУК АКТЛАРНЫҢ ҺӘМ НОРМАТИВ ХОКУК АКТ ПРОЕКТЛАРЫНЫҢ КОРРУПЦИЯГӘ КАРШЫ ЭКСПЕРТИЗАСЫН ҮТКӘРҮ ТӘРТИБЕ

## 1. Гомуми кагыйдәләр

1.1. Биредәге Тәртип Татарстан Республикасы Гражданнар оборонсы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгының (алга таба – Министрлык) норматив хокук актларының һәм норматив хокук акт проектларының, шулай да Министрлык белән эшләп чыгарыла торган Татарстан Республикасы норматив хокук акт проектларының (алга таба – актлар, акт проектлары) коррупциягә каршы экспертизасын үткәрү процедурасын билгеләп куя.

1.2. Коррупциягә каршы экспертиза “Норматив хокук актларның һәм норматив хокук акт проектларының коррупциягә каршы экспертизасы турында” Федераль законга, 2009 ел 24 нче декабрь № 883 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карары белән расланган Аерым норматив хокук актларның һәм норматив хокук акт проектларының коррупциягә каршы экспертизасын үткәрү тәртибенә, биредәге Тәртипкә туры китереп, Русия Федерациясе Хөкүмәте белән билгеләнгән методика (алга таба – методика) буенча үткәрелә.

1.3. Коррупциягә каршы экспертизага килгән актлар (акт проектлары) коррупциягә каршы экспертизага килгән норматив хокук актларны һәм норматив хокук акт проектларын исәпләү журналында (алга таба – Журнал) теркәлә (биредәге Тәртипкә кушымта № 1).

1.4. Коррупциягә каршы экспертизаның нәтиҗәләре буенча биредәге Тәртипнең 2 нче кушымтасындагы форма буенча йомгак төзелә. Анда түбәндәге мәгълүматлар языла:

экспертизага китерелгән акт реквизитлары (акт проектының исеме);

экспертизаны үткәрер өчен нигез;

актта (акт проектында) коррупциоген факторлар булу яисә булмау;

коррупциоген факторлар булган актның (акт проектының) билгеле фикерләре;

коррупциогенлыкны юк итәр өчен хокук нормаларының тәгъбирен үзгәртү яисә аерым нормаларны чыгарып ташлау буенча тәкъдимнәр.

## 2. Министрлык актларының коррупциягә каршы экспертизасы

2.1. Министрлык актларының коррупциягә каршы экспертизасы Министрлыкның хокук белән тәэмин итү бүлеге белән үткәрелә. Норматив хокук актларның һәм норматив хокук акт проектларның коррупциягә каршы экспертизасын үткәрү өчен җаваплы (алга таба – җаваплы шәхес) булган Министрлыкның хокук белән тәэмин итү бүлегенең башлыгы Татарстан Республикасы Гражданнар оборонсы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министры (алга таба – Министр) боерыгы белән билгеләп куела.

2.2. Министрлык актларының коррупциягә каршы экспертизасы Министрлыкның структура бүлекләре белән актларны куллануны мониторинглаганда актларда коррупциоген факторларны тапканда җаваплы шәхес белән үткәрелә, шулай да актларда коррупциоген факторлар булу турында мәгълүматны кайсы да булса ысул белән алган вакытта. Шулай да актлар Министрлык җитәкчелеге белән экспертиза үткәрелер өчен юнәлтелә ала.

Коррупциягә каршы экспертиза көчен югалткан яисә гамәлдән чыгарылган норматив хокук актлар ягына үткәрелми.

2.3. Актларны туры килгән мәгълүмат килү яисә Министрлык җитәкчелеге актны җибәрү көнендә җаваплы шәхес терки.

2.4. Актның коррупциягә каршы экспертизасы Журналда актны теркәү көненнән бирле ун көнлек вакыт эчендә үткәрелә.

Актның коррупциягә каршы экспертизасының нәтиҗәләре җаваплы шәхес белән, биредәге Тәртипнең 1.4 пунктына туры китереп, төзелә торган йомгак буларак рәсмиләштерелә һәм Журналга языла.

Коррупциягә каршы экспертизасының нәтиҗәләре турында йомгакны төзү һәм имзалау көненнән бирле бер эш көненнән соңга калмыйча экспертизаны җибәргән шәхескә хәбәр ителә.

2.5. Актта коррупциоген факторлар булу турында йомгак җаваплы шәхес белән төзү һәм имзалау көненнән бирле бер эш көненнән соңга калмыйча Министрга җибәрелә.

2.6. Актта коррупциоген факторлар булу турында йомгакның нәтиҗәләре буенча Министр актка үзгәрешләр кертү кирәге яисә акт көчен югалтуны тану турында карар чыгара.

2.7. Биредәге актны чыгаруга инициатива куйган структура бүлеге биредәге Тәртипнең 2.6 пунктында билгеләнгән карарны Министр кабул иткән көннән бирле өч көнлек вакыт эчендә туры килгән Министрлык актының проектын хәзерли һәм аны җаваплы шәхескә коррупциягә каршы экспртизасына җибәрә. Шундый проектның коррупциягә каршы экспертизасы биредәге Тәртипнең 3 нче бүлегенә туры китереп үткәрелә.

## 3. Министрлыкның акт проектларының, шулай да Министрлык белән эшләп чыгарыла торган Татарстан Республикасы акт проектларының коррупциягә каршы экспертизасы

3.1. Министрлыкның акт проектларының, шулай да Министрлык белән эшләп чыгарыла торган Татарстан Республикасы акт проектларының коррупциягә каршы экспертизасы (алга таба – акт проектлары) хокукый экспертизаны үткәргәндә Министрлыкның хокук белән тәэмин итү бүлегенең җаваплы шәхесе белән үткәрелә.

3.2. Акт проектларын коррупциягә каршы экспертизаны үткәрер өчен Министрлыкның проектны эшләп чыгару өчен җаваплы булган структура бүлегенең вазифалы шәхесе җибәрә.

3.3. Килгән акт проектларын җаваплы шәхес килү көнендә Журналда терки.

Коррупциягә каршы экспертиза проектны теркәү көненнән бирле ун көнлек вакыт эчендә үткәрелә.

3.4. Коррупциягә каршы экспертизаның нәтиҗәләре биредәге Тәртипнең 1.4 пунктына туры китереп, җаваплы шәхес төзи торган йомгак белән рәсмиләштерелә һәм Журналга языла.

Коррупциоген факторлар булу турында йомгак ул төзелү көнендә проектны җибәргән структура бүлегенә тапшырыла.

3.5. Коррупциоген факторлар булган вакытта проектны хәзерләгән структура бүлеге йомгакны алу көненнән бирле өч көнлек вакыт эчендә проектны эшләп бетерә һәм кабат коррупциягә каршы экспертизаны үткәрер өчен җаваплы шәхескә җибәрә.

3.6. Кабат коррупциягә каршы экспертиза биредәге Тәртипнең 3.4 һәм 3.5 пунктларында билгеләнгән тәртиптә эшләп бетерелгән проектны алу көненнән бирле өч көнлек вакыт эчендә үткәрелә.

## 4. Министрлык актларының һәм акт проектларының бәйсез коррупциягә каршы экспертизасы

4.1. Рәсми рәвештә чыгарылган һәм “Интернет” мәгълүмат һәм телекоммуникация челтәрендә Министрлыкның mchsrt@tatar.ru рәсми сайтына (алга таба – сайт) кертелгән Министрлыкның норматив хокук актлары һәм Министрлык эшләп чыгарган норматив хокук акт проектлары бәйсез коррупциягә каршы экспертизаның объектлары булып тора.

4.2. Министрлыкның акт проектларының коррупциягә каршы экспертизасын үткәрер өчен Министрлыкның акт проектын эшләп чыгару өчен җаваплы структура бүлеге акт проектын Министрлыкның хокук белән тәэмин итү бүлегенә карап тикшерүгә җибәрә. Җаваплы шәхес акт карап тикшерүгә килү көненә туры килә торган эш көне эчендә эксперт йомгакларын җибәрү өчен адресны (шул исәптән электрон почта адресы), шулай да бәйсез коррупциягә каршы экспертиза нәтиҗәләре буенча йомгакларны алу башлану һәм тәмамлану даталарын билгеләп, акт проектын сайтка кертә.

4.3. Сайтка кертелгән акт проектларының бәйсез коррупциягә каршы экспертизасын үткәрү срогы ун эш көненнән ким булмыйча тәшкил итә.

4.4. Актның (акт проектының) бәйсез коррупциягә каршы экспертиза нәтиҗәләре буенча Министрлыкка килгән йомгак (алга таба – йомгак) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының бердәм идарәара электрон документ әйләнеш системасында теркәлә һәм Министрлыкның актны (акт проектын) хәзерләү өчен җаваплы структура бүлегенә карап тикшерүгә җибәрелә.

4.5. Бәйсез коррупциягә каршы экспертизаның нәтиҗәләре буенча йомгак тәкъдим характерын йөртә һәм ану алу көненнән бирле 15 көнлек срок эчендә Министрлык белән мәҗбүри карап тикшерелергә тиеш. Карап тикшерү нәтиҗәләре буенча бәйсез коррупциягә каршы экспертизаны үткәргән юридик яисә физик шәхескә дәлилләнгән җавап җибәрелә, ләкин йомгакта табылган коррупциоген факторларны юк итү юлы турында тәкъдимнәр булмау очракларыннан тыш.

4.6. Акт проектының бәйсез коррупциягә каршы экспертизасын үткәргәндә табылган коррупциоген факторларны эшләп чыгаручы акт проектын эшләп бетерү стадиясендә юк итә.

4.7. Бәйсез коррупциягә каршы экспертиза йомгагында язылган искәрмәләрне юк иткәннән һәм тәкъдимнәрне исәпкә алганнан соң Министрлыкның акт проектын хәзерләү өчен җаваплы структура бүлеге, бәйсез коррупциягә каршы экспертиза нәтиҗәләре буенча килгән йомгакларны кушып, акт проектын Министрлыкның хокук белән тәэмин итү бүлегенә кабат карап тикшерүгә тапшыра. Кабат карап тикшерү өч көнлек срок эчендә башкарыла.

4.8. Әгәр актта коррупциоген факторлар табылса, Министрлыкның биредәге актны хәзерләгән структура бүлеге йомгакны Министрлыкта теркәү көненнән бирле өч көнлек срок эчендә актка үзгәрешләр кертү буенча яисә акт көчен югалтканны тану турында чаралар кабул итә.

4.9. Министрлык  бәйсез коррупциягә каршы экспертизаның Министрлык актларында һәм Министрлык эшләп чыгарган акт проектларында коррупциоген факторлар булу турында белдергән нәтиҗәләре белән риза булмаса,  Министрлык законнар белән билгеләп куелган тәртиптә биредәге актларны (акт проектларын), бәйсез коррупциягә каршы экспертиза йомгагын һәм үзенең риза булмавын дәлилләү белән аңлатма язуны кушып, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына коррупциягә каршы экспертизага җибәрә.

4.10. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының законнар чыгару инициативасы тәртибендә Русия Федерациясе Федераль Җыелышының Дәүләт Думасына кертелә торган Министрлык эшләп чыгарган федераль закон проектларында, Татарстан Республикасы закон проектларында, Татарстан Республикасы Президентының указ проектларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карар проектларында коррупциоген факторлар булу турында белдергән коррупциягә каршы экспертизаның, шул исәптән бәйсез дә, нәтиҗәләре белән эшләп чыгаручы риза булмаган очракта, эшләп чыгаручы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты белән билгеләп куелган тәртиптә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына биредәге норматив хокук акт проектларын карап тикшерүгә тапшыра.

Кушымта № 1
Татарстан Республикасы
гражданнар оборонасы эшләре
һәм гадәттән тыш хәлләр
министрлыгында норматив хокук
актларның һәм норматив хокук
акт проектларының коррупциягә
каршы экспертизасын үткәрү
тәртибенә

Журнал
Коррупциягә каршы экспертизага килгән норматив хокук актлар һәм норматив хокук акт проектларын исәпләү журналы

| Экспертизага килгән актның (акт проектының) килү датасы | Актны (акт проектын) тапшырган структура бүлеге | Актның (акт проектының) исеме | Коррупциоген нормалар булу/булмау | Йомгакны төзү датасы | Искәрмәләр (кабат экспертизаны үткәрү турында мәгълүмат, кабат экспертиза нәтиҗәләре буенча йомгакны төзү датасы) (акт проектлары ягына) |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |

Кушымта № 2
Татарстан Республикасы гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгында норматив хокук актларның һәм норматив хокук акт проектларының коррупциягә каршы экспертизасын үткәрү тәртибенә

Коррупциягә каршы экспертизаның йомгагы

______________________________________________________________________

(норматив хокук актның реквизитлары яисә
норматив хокук акт проектының исеме)

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

“Норматив хокук актларның һәм норматив хокук акт проектларының коррупциягә каршы экспертизасы турында” 2009 ел 17 нче июль № 172-ФЗ Федераль законына, “Аерым норматив хокук актларның һәм норматив хокук акт проектларының коррупциягә каршы экспертизасын үткәрү тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында” 2009 ел 24 нче декабрь № 883 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карары белән расланган Аерым норматив хокук актларның һәм аларның проектларының коррупциягә каршы экспертизасын үткәрү тәртибенә туры китереп, “Норматив хокук актларның һәм норматив хокук акт проектларының коррупциягә каршы экспертизасы турында” 2010 ел 26 нчы февраль № 96 Русия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган Норматив хокук актларның һәм норматив хокук акт проектларының коррупциягә каршы экспертизасын үткәрү методикасына карап, актта коррупциоген факторларны табу һәм аннары аларны юк итү максаты белән Министрлыкның хокук белән тәэмин итү бүлеге актның коррупциягә каршы экспертизасын үткәрде.

Проектта коррупциоген нормалар булу яисә булмау:

______________________________________________________________________

Коррупциоген нормалар булган акт проектының билгеле фикерләре:

______________________________________________________________________

Коррупциогенлыкны юк итү өчен тәгъбирләрне үзгәртү яисә аерым нормаларны чыгарып ташлау буенча тәкъдимнәр

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

Җаваплы шәхес __________________________